**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКАИ ТАТАРСТАН**
пер. Школьный, д.5,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423627

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт,
Тойгуҗа авылы, Менделеев районы,
Татарстан Республикасы, 423627

Тел. (факс): (85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 28 октябренннән №7

2022 - 2023 елларның көзге-кышкы чорында
су объектларында кешеләрнең
куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәллләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, шулай ук Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә су объектларында бәхетсезлек очракларын профилактикалау һәм киметү максатларында

**КАРАР ҖИРӘ**:

1. ТойгуҖа авыл җирлеге территориясендә 2022-2023 елларның көзге-кышкы чорында су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын үткәрергә.
2. Гражданнарның җирлек сулыклары бозларына чыгуын 2022 елның 28 октябреннән боз барлыкка килү чорына, боз катламының куркынычсыз калынлыгына ирешүгә кадәр, тыярга.
Гражданнарның сулыклар бозларына чыгуы аның тулысынча формалашкан чоры башланганчы тыелган (бозның калынлыгы 7 см дан артык).
Су объектларында боз кичүләре зонасыннан тыш механик транспорт чаралары белән бозда йөрү һәм туктап тору тыела.
3. Гадәттә, җирлек тарафыннан боз өстеннән сулыклар аша чыгу өчен файдаланыла торган урыннарда, шулай ук кышкы көндә балык тотарга яратучыларның массакүләм чыгу урыннарында кисәтү язулы аншлаглар куярга.
Гомуми файдалану һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарда бозга чыгу куркынычы турында кисәтә торган мәгълүмат битләрен урнаштырырга.
4. Җирлек территориясендә гамәлдә булган предприятиеләр, учреждениеләр һәм бүлекчәләр җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:
- предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, бүлекчәләрнең сулыкларның бозлы өслекләренә чыгу куркынычы турында кисәтү эшләрен башкарырга;
- сулыкларда кешеләр үлеме очракларын булдырмауга юнәлтелгән башка чаралар күрергә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
6. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин